**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2447**
**09.04.2021**

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгына һәм Яр Чаллы шәһәрендә 2021 елның җәйге спорт сезонын ачуга багышланган XLVII традицион шәһәр җиңел атлетика эстафетасы үткәрү турында

Шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә, Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5631 номерлы карары белән расланган «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, халыкның ялын оештыру, киләчәктә җиңел атлетиканы популярлаштыру, спорт осталыгы дәрәҗәсен күтәрү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгына һәм Яр Чаллы шәһәрендә 2021 елның җәйге спорт сезонын ачуга багышланган XLVII традицион шәһәр җиңел атлетика эстафетасын (алга таба – эстафета) 2021 елның 30 апрелендә үткәрергә.

2. Расларга:

1) эстафетага әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 1 нче кушымтада каралганча;

2) эстафетага әзерлек һәм аны үткәрү буенча чаралар планын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) эстафета үткәрү турындагы нигезләмәне, 3 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә эстафетаны оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнарны финанслауны 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Массакүләм спорт» 11.02 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 105 340,00 (бер йөз биш мең өч йөз кырык) сум 00 тиен күләмендә, 4 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2021 елның 9 апрелендәге
2447 номерлы карарына
3 нче кушымта

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгына
һәм Яр Чаллы шәһәрендә 2021 елның җәйге спорт сезонын ачуга багышланган
XLVII традицион шәһәр җиңел атлетика эстафетасы үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгына һәм Яр Чаллы шәһәрендә 2021 елның җәйге спорт сезонын ачуга багышланган XLVII традицион шәһәр җиңел атлетика эстафетасы түбәндәге максатларда үткәрелә:

1) шәһәр халкын системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү;

2) көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау;

3) сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;

4) хәрәкәт активлыгының төрле формаларын пропагандалау;

5) спортка бәйле традицияләрне ныгыту.

2. Эстафета 2021 елның 30 апрелендә шәһәрнең Ф. Табиев яр буенда үткәрелә. Эстафетаны ачу парады 11 сәгать 00 минутта үткәрелә.

2 бүлек. Эстафетаны үткәрү шартлары

3. Эстафетада шәһәр оешмаларының җыелма командалары катнаша. Командалар саны чикләнмәгән. Командаларның составы:

1) 1-4 төркем – 13 кеше (8 ир-егет, 5 хатын-кыз) һәм 1 вәкил;

2) 5-6 төркем – 13 кеше (8 малай, 5 кыз) һәм 1 вәкил.

4. Эстафетада катнашу өчен оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган, табиб тарафыннан расланган заявкалар 2021 елның 29 апреленә кадәр эстафетага әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитетына ufis@list.ru бирелә. Оештыру комитеты составы Башкарма комитет карары белән раслана.

5. Бер катнашучы берничә йөгерештә катнашкан, башка команда составында чыгыш ясаган, теркәлүгә соңга калган, түш номеры булмаган очракта һәм катнашучылар эстафета таягын тапшыру зонасыннан чыккан өчен команданың нәтиҗәләре юкка чыгарыла.

6. Старт:

1) беренче йөгереш – белем бирү оешмаларының 6-7 нче сыйныф командалары – 11 сәгать 40 минутта;

2) икенче йөгереш – һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары һөнәри белем бирү оешмаларының командалары – 12 сәгать 20 минутта;

3) өченче йөгереш – белем бирү оешмаларының 8-11 нче сыйныф командалары – 13 сәгать 00 минутта;

4) дүртенче йөгереш – шәһәр оешмаларының командалары, спорт клублары, коммерцияле булмаган оешмалар, халыкның үзләре оештырган командалары, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле кешеләрнең командалары – 13 сәгать 30 минутта.

7. Командаларның саны аз булганда йөгерешләр берләштерелергә мөмкин.

8. Эстафетада катнашучылар бары тик бер генә йөгерештә катнашырга мөмкин.

9. Шәһәр оешмалары командаларында катнашучыларның, кайсы оешма өчен чыгыш ясыйлар, шунда төп эш урыны булырга тиеш.

10. Эстафетада катнашучыларны теркәү старт вакытына кадәр 20 минут алдан башкарыла.

11. Эстафета таягын тапшыру стартта билгеләнгән 20 метрлы зонада башкарыла.

3 бүлек. Эстафетага йомгак ясау

12. Эстафетада җиңүчеләр, команданың катнашучылары эстафетаның барлык этапларын үтү вакытының иң аз суммасы буенча, җиде төркем арасында түбәндәге таблица нигезендә билгеләнә:

| 1 төркем | 2 төркем | 3 төркем | 4 төркем | 5 төркем | 6 төркем |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 төркемчә – бер меңгә кадәр хезмәткәре булган оешмалар; 2 төркемчә – бер меңнән артык хезмәткәре булган оешмалар | югары белем бирү оешмалары | һөнәри белем бирү оешмалары | спорт клублары, коммерцияле булмаган оешмалар, халыкның үзләре оештырган командалары | белем бирү оешмаларының 8-11 нче сыйныфлары | белем бирү оешмаларының 6-7 нче сыйныфлары |

13. Призлы урыннар алган командалар, җиңүче команда катнашучылары, катнашучыларның һәр төркемендәге җиңүчеләр грамоталар, медальләр һәм кубоклар белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева